| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Красноборского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерже муниципаль районы**<br>**Красный Бор авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**07.02.2025** **№ 52-2**

«Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Әгерже муниципаль районының 22.11.2019 елның 53-1 номерлы Красный Бор авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 22.11.2019 елның 53-1 номерлы Красный Бор авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
39 статьяның 1 пунктындагы 13 абзацында «паспортлар тапшырыла» сүзләрен «паспортлар (паспорт проектлары) тапшырыла» сүзләренә алмаштырырга;
42 статьяның 3 пунктындагы 14 абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 42 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле яна уникенче абзац өстәргә:

«бюджет ассигнованиеләре ашыгыч гуманитар җавап бирү, гуманитар ярдәм йөкләрен китерү, халыкны эвакуацияләү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанс белән тәэмин итүгә яңадан бүленгән очракта.»;

Уникенче - унөченче абзацлар тиешенчә унөченче - ундүртенче абзацлар булып санала.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Красный Бор авыл җирлегенең махсус бирелгән мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.
Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл жирлеге башлыгы Е.А. Яковлева